КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 28 апрель г.Казань № 630

«Россия – Ислам дөньясы: KazanForum» XVII халыкара икътисадый форумы үткәрелә торган көннәрдә алкогольле продукцияне ваклап сатуны чикләү турында

«Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм әйләнештә йөртүне дәүләт тарафыннан җайга салу турында һәм алкогольле продукцияне куллануны (эчүне) чикләү хакында» 1995 елның 22 ноябрендәге 171-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum» XVII халыкара икътисадый форумы үткәрелгәндә иминлекне тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2026 елның 12 маеннан 17 маена кадәр “Россия - Ислам дөньясы: KazanForum” XVII халыкара икътисадый форумы үткәрелгән көннәрдә алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми, моңа “Россия - Ислам дөньясы: KazanForum” XVII халыкара икътисадый форумын үткәрүдә катнашкан территорияләрдә урнашкан сәүдә объектларында җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату керми, кушымта нигезендә.

2. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты, Татарстан Республикасы Лаеш һәм Спас муниципаль районнары башкарма комитетлары белән берлектә, кертелә торган чикләү турында халыкка мәгълүмат бирү эшен оештырырга.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүне, әйләнештә йөртүне һәм аларның сыйфатын дәүләт тикшерүендә тотуны тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясенә һәм, килештереп, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына йөкләргә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Премьер–министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2026 ел, 28 апрель, 630 нчы
карарына кушымта

«Россия - Ислам дөньясы: KazanForum» XVII халыкара икътисадый форумын үткәргәндә гамәлдә булган территорияләрдә урнашкан сәүдә объектлары урнашкан урын

| Т/с | Форум уздырганда файдаланыла торган территориядә урнашкан объектның адресы | Алкогольле продукцияне сатуны чикләү датасы | Алкогольле продукцияне ваклап сату рөхсәт ителми торган сәүдә объекты адресы |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | «Отель Арт» кунакханәсе,<br>Казан ш., Островский ур., 33 й. | 12.05.2026 – 17.05.2026 | Казан ш., Островский ур., 31 й.;<br>Университет ур., 4/34 й. |
| 2. | «Relita-Kazan» кунакханәсе,<br>Казан шәһәре, Декабристлар ур., 81Г й. | 12.05.2026 – 17.05.2026 | Казан ш., Декабристлар ур., 85, 88 йортлар; Ибраһимов проспекты, 56 й. |
| 3. | «Корстон» кунакханә сәүдә-күңел ачу комплексы,<br>Казан ш., Николай Ершов ур., 1А й. | 12.05.2026 – 17.05.2026 | Казан ш., Николай Ершов ур., 1А й. |
| 4. | «Гранд отель Казань» кунакханәсе,<br>Казан ш., Петербург ур., 1 нче й. | 12.05.2026 – 17.05.2026 | Казан ш., Петербург ур., 1, 9 й. |
| 5. | «Kazan Palace by TASIGO» 5* кунакханәсе,<br>Казан ш., Калинин ур., 3Б й. | 12.05.2026 – 17.05.2026 | Казан ш., Волков ур., 48/22 й. |
| 6. | «NEO Kazan Palace by TASIGO» 4* кунакханәсе,<br>Казан ш., Калинин ур., 3В й. | 12.05.2026 – 17.05.2026 | Казан ш., Волков ур., 48/22 й. |
| 7. | «Ногай» кунакханә комплексы,<br>Казан ш., Профсоюз ур., 16Б й. | 12.05.2026 – 17.05.2026 | Казан ш., Бауман ур., 21, 25 йортлар;<br>Кави Нәҗми ур., 3/9 й. |
| 8. | «Мано» кунакханәсе,<br>Казан ш., Чистай ур., 47а й. | 12.05.2026 – 17.05.2026 | Казан ш., Абдулла Бичурин ур., 11 й.;<br>Чистай ур., 43, 43А йортлар |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 9. | «Кристалл» кунакханәсе,<br>Казан ш., Рөстәм Яхин ур., 8 й. | 12.05.2026 –<br>17.05.2026 | Казан ш., Борхан Шаһиди ур., 1/15 й.; Сәетгалиев ур., 6, 6А йортлар |
| 10. | «Cosmos Kazan Hotel» кунакханәсе,<br>Казан ш., Лесгафт ур., 7 й. | 12.05.2026 –<br>17.05.2026 | Казан ш., Лесгафт ур., 6/57 й. |
| 11. | «Cort Inn Kazan Kremlin» кунакханәсе,<br>Казан шәһ., Карл Маркс ур., 6 й. | 12.05.2026 –<br>17.05.2026 | Казан ш., Карл Маркс ур., 3 й. |
| 12. | «АМАКС Сафар-отель» кунакханәсе,<br>Казан ш., Беряклы Гривки ур., 1 й. | 12.05.2026 –<br>17.05.2026 | Казан ш., Комсомольская ур., 2 й. |
| 13. | «Хәял» кунакханәсе,<br>Казан ш., Университет ур., 16 й. | 12.05.2026 –<br>17.05.2026 | Казан ш., Университет ур., 20 й. |
| 14. | «Универсиада авылы» Татарстан Республикасы дәүләт автоном учреждениесе,<br>Казан ш., Универсиада авылы, 16а й. | 12.05.2026 –<br>17.05.2026 | Казан шәһәре, Академик Парин урамы, 16, 22 йортлар |
| 15. | «Мөниб» кунакханәсе,<br>Казан ш., Ульянов-Ленин ур., 8 й. | 12.05.2026 –<br>17.05.2026 | Казан ш., Петербург ур., 42 нче й. |
| 16. | «Дон Кихот» кунакханәсе,<br>Казан ш., Б.Шахиди ур., 11 й. | 12.05.2026 –<br>17.05.2026 | Казан ш., Б.Шахиди ур., 1/15, 26, 17 йортлар;<br>Мәскәү ур., 48 й.;<br>Таҗи Гыйззәт ур., 8 й.;<br>Чернышевский ур., 37 й. |
| 17. | Казан Ратушасы,<br>Казан ш., Карл Маркс ур., 33 й. | 15.05.2026 | Казан ш., Зур Кызыл ур., 29 й. |
| 18. | «Казан» агросәнәгать паркы» ачык акционерлык җәмгыяте<br>Казан ш., Аграр ур., 2 й. | 12.05.2026 –<br>17.05.2026 | Казан ш., Аграр ур., 2 й. |
| 19. | «Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры» дәүләт бюджет учреждениесе | 14.05.2026 –<br>15.05.2026 | Казан ш., Һади Такташ ур., 41, 45а, 66, 105 йортлар |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | Казан ш., Һади Такташ ур., 74 й. | | |
| 20. | Бәшир Рәмиев исемендәге IT-парк,<br>Казан шәһәре, Спартак ур., 2 й. | 13.05.2026 – 14.05.2026 | Казан ш., Һади Такташ ур., 2, 77 йортлар;<br>Спартак ур., 6 й.;<br>Марсель Сәлимҗанов ур., 12А, 15/8В, 17 й. |
| 21. | Казан ипподромы,<br>Казан ш., Альберт Камалеев проспекты, 27/1 й. | 16.05.2026 | Казан ш., Калинин ур., 1 й.<br>А.Камалеев проспекты, 30, 32, 34, 30 йортлар |
| 22. | «Казан» халыкара аэропорты» акционерлык җәмгыяте,<br>Лаеш районы, Столбище авыл җирлеге | 12.05.2026 – 17.05.2026 | Лаеш районы, Столбище авыл җирлеге, аэропорт территориясе, 549 бина |
| 23. | «Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе,<br>Болгар ш., Назаровлар ур., 67 й. | 17.05.2026 | Болгар ш., Гордеев ур., 6 й.;<br>Базар ур., 6 й.;<br>Смирнов ур., 10Б, 109Д йортлар |

______________________________